ГЛАВА КИЛЬДЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КИЛДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

02.04.2024 с. Кильдеево 2

«Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлегенең Уланово авылында гражданнар җыенының 2023 елның 25 октябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү 22.11.2013 ел № 90 тәртибенең 2 пункты (29.11.2023 ел № 1532 редакциясендә) нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. «Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлегенең Уланово авылындагы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 26 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 13 апреленә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга :

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлегенең Уланово авылындагы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 26 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:
- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау
(Уланово авылында үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системасын норматив хәлгә китерү).

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Уланово авыл клубында гражданнар җыенын Уланово авылы, Заозерная урамы, 44 йорт адресы буенча 14.00 сәгатьтә уздырырга.
4. Килди авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге башлыгы В. М. Бурдин